# Балтачта районкүләм чыгарылыш кичәсе узды

«Сабантуй» ял паркында районның чыгарылыш кичәсе гөрләде. – Бүгенге истәлекле көнегез белән чын күңелемнән котлыйм, – диде район башлыгы Рамил Нотфуллин чыгарылыш укучыларына мөрәҗәгать итеп.Район җитәкчеләре дә укучыларга киләчәктә гел ак юллар гына теләде, медаль алучыларны, бердәм дәүләт имтиханнарында 90 һәм аннан югары баллар җыючыларны сәхнәгә чакырып, тәбрикләде.

